**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Чуаш-Кичүе авыл жирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Алькеевского муниципальный район**
**СОВЕТ Чувашско-Бродского**
**сельского поселения**

422882, Чуаш-Кичүе авылы
Яшьләр урамы – 12 й
Факс (84346) 75-2-17 Тел. (84346) 75-2-12

422882, с. Чувашский Брод, ул. Молодежная, д. 12
факс( 884346) 75-2-17, тел. (884346) 75-2-12

**РЕШЕНИЕ** Чуаш-Кичүе авылы **КАРАР**

2022 елның 9 марты 42 №

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Чуаш- Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән), 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
« Чуаш-Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85,86 статьясы нигезендә Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы “Чуаш-Кичүе авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 11 октябрендәге 102 номерлы карары ( 2019.11.11, 18№, 2020.23.10, 8№ үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Чуаш-Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (1нче кушымта).
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Чуаш-Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Чуаш-Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Чуаш-Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Чуаш-Кичүе авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы, Әлки районы, Чуаш-Кичүе районы, Яшьләр ур., 12 йорт (җирле үзидарә бинасы), Чуаш-Кичүе районы, Яшьләр ур., 2А йорт (мәдәният йорты бинасы) адресы буенча махсус җиһазландырылган стендларда урнаштырырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru. сайтында һәм

Татарстан Республикасының рәсми pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
« Чуаш-Кичүе авыл җирлеге»
муниципаль берәмлек башлыгы: Р.Н.Зайдуллин

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы "Чуаш -Кичүе авыл" муниципаль
берәмлеге Советы карарына1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Чуаш-Кичүе авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**5 статьяда (җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре):**

5 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;».

**6 статьяда (җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә җирле үзидарә органнары хокуклары):**

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:
«17) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

**10 статьяда (җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның турыдан-туры катнашуы):**

10 статьяга түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) инициатив проектлар;».

**II бүлеккә 15.1 статьясын түбәндәге редакциядә өстәргә:**

**«15.1 статья. Инициатив проектлар**

1. Җирлек халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле администрациягә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган җирлек территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Инициатив проектны кертү инициативасы белән уналты яшькә җиткән һәм тиешле Җирлек территориясендә яшәүче кимендә ун гражданы булган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, авыл торак пункты старостасы (алга таба - проект инициаторлары) чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең

минималь саны Җирлек Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Җирлек Советының норматив хокукый акты нигезендә проект инициаторы булу хокукы шулай ук тиешле Җирлек территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициатив проект үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

1) җирлектә яисә аның өлешендә яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблеманы тасвирлау;

2) әлеге проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгымнарны алдан исәпләү;

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырылган срогы;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) эштә катнашуы турында белешмә;

7) инициатив түләүләрнең планлаштырылган күләменнән тыш, әлеге акчаларны инициатив проектны гамәлгә ашыруга куллану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләменә күрсәтү;

8) җирлек Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә инициатив проект гамәлгә ашырылачак җирлек территориясенә яисә аның өлешенә күрсәтмә;

9) Җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Җирлек Башкарма комитетына кертелгәнче инициатив проект гражданнар җыенында, җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, инициатив проект турында фикер алышу, җирлектә яшәүчеләрнең яисә аның өлешенең мәнфәгатьләренә туры килүен билгеләү, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгын билгеләү, шулай ук инициатив проектны хуплау өчен гражданнар җыенында, җыелышында яисә конференциясендә каралырга тиеш. Шул ук вакытта бер җыенда, бер җыелышта яки гражданнарның бер конференциясендә берничә инициатив проектны карау мөмкин.

Җирлек Советының норматив хокукый акты белән шулай ук гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау мөмкинлеге каралырга мөмкин.

Инициатив проектны гамәлгә керткәндә проект инициаторлары Җирлекнең Башкарма комитетына гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе беркетмәсен, гражданнардан сораштыру нәтиҗәсен һәм (яисә) инициатив проектка Җирлек халкы яисә аның өлеше тарафыннан ярдәм күрсәтүне раслый торган имзаланган кәгазьләрне беркетә.

5. Инициатив проектны җирле администрациягә кертү турындагы мәгълүмат инициатив проект җирле администрациягә кертелгәннән соң өч эш көне эчендә әлеге статьяның 3 өлешендә, шулай ук проект инициаторлары турында күрсәтелгән белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга Җирлекнең башкарма комитетына кисәтү һәм тәкъдимнәрен, биш эш көненнән артмаган вакытта, тәкъдим итү срогын күрсәтеп, тәкъдим итү мөмкинлеге турында хәбәр ителә. Искәрмә һәм тәкъдимнәрен уналты яшькә җиткән Җирлек халкы җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат составына әлеге җирлек

кергән муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла. Авыл торак пункты гражданнарына әлеге мәгълүмат авыл торак пункты старостасы аша җиткерелергә мөмкин.

6. Инициатив проект Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан аны керткән көннән алып 30 көн эчендә һичшиксез каралырга тиеш. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм аның өстендә эшләүне җирле бюджет турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә тиешле максатларга җирле бюджет проектын төзү һәм карау тәртибенә туры китереп (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) дәвам итәргә;

2) инициатив проектка ярдәм итүдән баш тартырга һәм инициатив проектка ярдәм итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, проектны инициаторларына кире кайтарырга.

7. Җирле администрация инициатив проектка ярдәм итүдән баш тарту турындагы карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

1) инициатив проектны кертү һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның Россия Федерациясе федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары таләпләренә, муниципаль берәмлек уставына туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарында кирәкле вәкаләтләр һәм хокуклар булмау сәбәпле, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) аларны формалаштыру чыганагы булып инициатив түләүләр тормаса, инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган акча күләмендә җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк ысул белән хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проект конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану.

8. Җирлекнең башкарма комитеты ә әлеге статьяның 7 өлешендәге 5 пунктында каралган очракта проект инициаторларына бергәләп инициатив проектны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә, шулай ук аны компетенцияләре нигезендә җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы карамагына тәкъдим итәргә хокуклы.

9. Инициатив проектларны күрсәтү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе Совет (Җирлек Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены) тарафыннан билгеләнә.

10. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен чыгарыла торган инициатив проектларга карата инициатив проектта булырга тиешле белешмә составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26_1 статьясындагы 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 өлешләре таләпләре кулланылмый.

11. Җирлекнең башкарма комитетына эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлап берничә инициатив проект кертелгән очракта, җирле администрация конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проект инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү төзү һәм эшчәнлек тәртибе Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә. Коллегия органның (комиссиянең) составы

Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан төзелә. Мондый чакта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми санының яртысы Җирлек Советы тәкъдиме нигезендә билгеләнергә тиеш. Проект инициаторларына һәм аларның вәкилләренә коллегиаль орган (комиссия) конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда инициатив проектны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проект инициаторлары, тиешле Җирлек территориясендә яшәүче гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар инициатив проектны гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган формада иҗтимагый контрольне гамәлгә ашырырга хокуклы.

14. Җирлек Башкарма комитетының инициатив проектын карау, инициатив проектны гамәлгә ашыруның барышы, шул исәптән акчаларны куллану, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Җирлек Башкарма комитетының инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турында хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә Җирлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Күрсәтелгән мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат составына әлеге җирлек кергән муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла. Авыл торак пунктында гражданнарга күрсәтелгән мәгълүматны авыл торак пункты старостасы җиткерергә мөмкин.»;

**19 статья (гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар):**

19 статьяның 11 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
«11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау кагыйдәләре проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир биләмәләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану рөхсәт ителгән бер төрне мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә»;

**20 статьяда (Гражданнар җыелышы):**

1 пунктта «һәм Җирлек җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары» сүзләреннән соң «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу» сүзләрен өстәргә;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән шушы территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициатив проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

**22 статьяда (Гражданнар җыены):**

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасын өстәргә:
«4.1) 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирлек составына керә торган торак пункт территориясе өлешендә;»;

3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) авылара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча яңа төзелгән җирлектә»;

4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
«4. Әлеге статьяның 3 пунктындагы 4.1 пунктчасында каралган очрактан тыш, гражданнар җыены җирлек башлыгы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә яки җирлектә яшәүчеләрнең 10 кешедән ким булмаган төркеме инициативасы буенча чакырылырга мөмкин.»;

4 пунктның 4.1 пунктчасы түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:
«Әлеге статьяның 3 пунктының 4.1 бүлегендә каралган гражданнар җыены, 10 кешедән дә ким булмаган санда торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче кешеләр төркеме инициативасы белән җирлек советы тарафыннан чакырылырга мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре Җирлек Советы карары белән җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләләрне хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләрен яклау критериеннән чыгып билгеләнә.»;

9 пунктта «торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясе өлешләре)» сүзләрен өстәргә;

**23 статьяда (Гражданнарны сораштыру):**

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданнардан инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән Җирлектә яисә аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлектә яисә аның өлешендә яшәүчеләр - шушы инициатив проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

5 пунктның беренче абзацында «Җирлек Советы. Карарда» сүзләрен «Җирлек советы» сүзләренә алмаштырырга. Гражданнардан сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлек сайты кулланылырга мөмкин. Карарда»;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:
«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлек сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

7 пунктның 1 пунктчасында «җирлекнең җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «яисә җирлектә яшәүчеләрне» сүзләрен өстәргә;

16.1 статьяның 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасын өстәргә:
«4.1) авыл торак пунктында яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча инициатив проект кертү инициативасы белән чыгыш ясарга хокуклы;»;

**38 статьяда (Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату):**

1 өлешнең 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
«7) Россия Федерациясе гражданлыгын яки чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт бирү тәре яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданына башка документ булу;»

**44 статьяда (Җирлек башлыгы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктату):**

44 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«44 статья. Җирлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Җирлек башлыгы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән эштән китү;

3) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 741 статьясы нигезендә эштән китү;

4) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан ваз кичү;

5) суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә эшкә сәләте чикләнгән дип тану;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

7) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керү;

8) даими яшәү өчен Россия Федерациясеннән китү;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын яки чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт биру төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданына башка документ булу;»

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

11) суд тәртибендә сәламәтлек торышы буенча Җирлек башлыгы вәләкатләрен гамәлгә ашырырга сәләтсез дип билгеләү;

12) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгәндә;

13) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү аркасында муниципаль берәмлектә сайлаучылар саны 25 проценттан күбрәккә арту.

2. Җирлек башлыгының вәкаләтләре шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы, аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары 2013 елның 7 маендагы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында»79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тыюны үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалтуга бәйле рәвештә вакытыннан алда туктатыла.

3. Муниципаль берәмлек вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры тәмамланганчы алты айдан да кимрәк вакыт калган булса, Җирлек башлыгын сайлау яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында гамәлгә ашырыла.

4. Җирлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Җирлекнең яңа башлыгы Җирлек Советының якындагы утырышында, вәкаләтләр шул рәвешле туктатылган көннән алып алты айдан артмаган срокта сайлана.

Җирлекнең яңа Башлыгы сайлана торган Җирлек Советы утырышын Җирлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән алып алты ай узгач иң өлкән Җирлек Советы депутаты алып бара.

Әгәр Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге уңай тавыш бирсә, депутат Җирлекнең башлыгы итеп сайланган санала.

5. Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки аңа карата суд карары буенча сак астына алу рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерелгән очракта, аның вәкаләтләрен Җирлек башлыгы урынбасары башкара.

Җирлек башлыгы урынбасары булмаганда Җирлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча депутатлар, депутатларның инициатив төркемнәре тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан җирлек Советының якындагы утырышында сайланган Җирлек Советы депутаты башкара.

Җирлек башлыгы, Җирлек башлыгы урынбасары, яки Җирлек Советы депутаты тарафыннан вәкаләтләр башкару срогы муниципаль берәмлекнең элеккеге башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән алып алты айдан арта алмый.

**47 статьяда (Башкарма комитет вәкаләтләре):**

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 19 пунктча өстәргә:

«19) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.» ;

Уставның 47 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:
13) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләреннән файдалануны, саклауны, урманнардан файдалануны оештыру;

47 статьяның 3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:
«3. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган булып тора.
1. Муниципаль контроль өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә керә:
1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;
2) муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;
3) әлеге Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.
2. Җирле әһәмияттәге, муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эчендәге бүленеше булган шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар, муниципаль округлар мәсьәләләре буенча муниципаль контрольнең тиешле төрләрен гамәлгә ашыруны җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә тапшыру
Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләрен җирлекнең башкарма комитеты органнарына мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә йөкләргә мөмкин.
Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләрне оештыру һәм уздыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата муниципаль контрольне гамәлгә ашыру 2008 елның 26 декабрендәге«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.».

**56 статьяда (Җирлек Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре):**
56 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашырмаучы Җирлек Советы депутатына, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр 2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында вәкиллекле орган депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Җирлек Советы карарлары белән билгеләнә.
2. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашырмаучы Җирлек Советы депутатына озынлыгы тулаем алганда аена ике һәм алты эш көненнән кимрәк булмаган чорга эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.».

**63 статьяда (Җирлекнең муниципаль хокукый актлары системасы):**

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1, 4.2 пунктчалар өстәргә:

«4.1. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, тиешле Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә экспертиза үткәрелергә мөмкин.;
4.2. Эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга һәм аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль кысаларында гамәлгә ашыруга, административ җаваплылыкка тартуга, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр, аккредитация, бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләрен бирүгә бәйле муниципаль норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне кулланууны билгеләү һәм бәяләү тәртибе (алга таба - мәҗбүри таләпләр) 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 247-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне куллану принципларын исәпкә алып муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә».

**66 статьяда (Муниципаль хокукый актларны әзерләү):**

4 пункка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

"3) гадәттән тыш хәлләр вакытында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары".

4 пунктта «эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар» сүзләрен «эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар» сүзләренә алмаштырырга.

5 пунктта «инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «башка икътисадый эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга.

**78 статьяда (Җирлектә бюджет процессы):**

7 өлешнең 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешүе юнәлешен билгели торган документларда;»

78 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

**80 статьяда (Гражданнарның үзара салым акчалары):**

1 пунктта «торак пункт» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясе өлешләре)» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «4.1 пунктында» сүзләрен «4.1 һәм 4.3 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.

**XIII бүлекне түбәндәге эчтәлекле 80.1 статьясы өстәргә:**

**«80.1 статья. Инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан һәм башкача тәэмин итү**

1. 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясында каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән инициатив түләүләр күләмнәрен һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпкә алып төзелгән, муниципаль берәмлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән инициатив проектларны гамәлгә ашыруга җирле бюджет турында карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре булып тора.

2. Инициатив түләүләр астында гражданнарның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә берләшкән юридик затларның конкрет инициатив проектларны гамәлгә ашыру максатларында. ихтыярый нигездә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетка күчерелә торган акчалары аңлашыла.

3. Инициатив проект гамәлгә ашырылмаган очракта, инициатив түләүләрне җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча инициатив проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициатив түләүләрнең калган өлеше, күрсәтелгән түләүләрне җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш.

Җирле бюджетка күчерелгән затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициатив түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициатив проектларны гамәлгә ашыру шулай ук кызыксынган затларның ихтыярый мөлкәти һәм (яисә) хезмәттә катнашу рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин.».

**87 статьяда (Җирлек Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар)**

87 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек Уставы, әлеге Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт Дәүләт теркәве узганнан соң рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм Җирлек территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда (PRAVO.TARSTAN.RU), шулай ук Россия Юстиция министрлыгы «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар»порталында (http://pravo-minjust.ru, http://pravo-минюст.рф) рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән) үз көченә керә. Җирлек башлыгы теркәлгән Җирлек Уставын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан Җирлек Уставы, 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт турында белешмәләр кертү хакында хәбәрнамә кергән көннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.»